| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗЕЛЕНАЯ РОЩА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.09.2019 ел №53

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Зелёная Роща авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 9 гыйнварында кабул иткән “Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 3нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 26 июлендә кабул ителгән “Федераль мәгълүмати адреслар системасы турындагы”һәм “Россия Федерациясенең җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында”гы №227-ФЗ законына таянып, законга туры китерү максатында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Зелёная Роща авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 9 гыйнварында кабул иткән “Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 3нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5нче пунктның 3нче абзацында “планлы структура элементын (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементын” дигән сүзләрне “урам -юл челтәре элементын һәм (яки) планлы структура элементы атамасын (кирәк булганда)” дигән сүзләр белән алыштырырга.

1.2. 1.5нче пунктның 5нче абзацын түбәндәге басмада бәян итәргә:
“адреслаштыру объекты – капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган адреслаштыру объектлары исемлегендә каралган башка объект;”.

2. Карар текстының башка өлешен үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Д.М. Хикмәтов**